СОВЕТ ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

21 ноябрь 2024 ел № 126

“Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Тойгуҗа авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан, муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип тану турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.2 өлеше һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, «Муниципаль хезмәт турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан, муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2023 елның 17 мартындагы 10/13-09/1230 номерлы аңлатмалары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан, муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советының 2022 елның 4 июлендәге 51 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны " Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча https://mendeleevsk.tatarstan.ru « Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Тойгуҗа авыл җирлеге Советы рәисе Р.А. Сафин